“Татарстан яшьләре”нә алдагы ярты еллыкка язылу бәясе шушы елның 1 маеннан 966 сумга күтәрелә!

1 майга кадәр язылучылар өчен бәя элеккечә - 294 сум.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Газета-журнал бәяләре Татарстанда чагыштырмача түбән булсын өчен хөкүмәтебез быел 240 миллион сум дотация билгеләгән иде. Бәяләрнең тыелгысыз үсүе аркасында дотацияне 420 миллионга җиткерергә туры киләчәк. Ләкин дәүләт казнасының мөмкинлекләре чиксез түгел, шуңа күрә 1 майдан газета-журналларга язылу бәяләре күтәрелә.

Хөрмәтле укучыларыбыз, ашыга төшегез! Бәясе арзан чакта “Т.Я.”га язылып калыгыз!

Татарстан яшьләре

N 44

(8766)

СИШӘМБЕ

13 апрель, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Референдумга ни өчен барып йөрисе юк

Татарстан өчен иң дөрес юл, әлбәттә, Мәскәү властьларының референдум белән бәйле авантюрасына бердәм рәвештә бойкот белдерү булыр иде. Ант итеп әйтәм, референдум нинди генә нәтиҗә белән тәмамланса да, Россия хакимиятендә бернәрсәне дә үзгәртмәячәк. Бары тик сайлаучыларның сайлауда катнашмаулары гына гаҗиз булган халыкка ниндидер бер өмет чаткысы бирүе мөмкин. Мондый нәтиҗә халык ышанычын акламаган һәм аны тәмам югалткан хәзерге Россия хакимиятенең бөтен тармаклары да отставкага китәргә тиеш дигәнне аңлатачак. Бу очракта яңа сайлаулар котылгысыз, гәрчә РФ өчен моның зарурлыгы референдумсыз да ап-ачык билгеле югыйсә.

Сүз уңаеннан, татарстанлылар өчен РФ гражданлыгы турында берничә сүз. Татарстан Конституциясе безгә Россия гражданлыгына “ия булу” хокукын да бирә. Әмма ул концептуаль яктан шундый итеп төзелгән, анда РФ гражданлыгы 19 маддәнең абсолют изоляцияләнгән булуы аркасында тулысынча һавада “асылынып” кала. Республиканың конституция кимлеге үз территориясендә Россия гражданлыгын тормышка ашыру механизмын карамый. Юриспруденциядә “эффектив гражданлык” төшенчәсе бар. Ә менә Татарстан территориясендә эффектив гражданлык бары берәү - Татарстан гражданлыгы гына. Ә икенче гражданлык запастагы кебек кенә. Шуңа күрә дә мин милләтче радикалларның, Россия гражданлыгын тагып, безне саттылар, дип ыңгырашуларын кабул итә алмыйм. Әйтергә кирәк, безнең РФ гражданлыгыннан баш тартырга тулы хакыбыз бар. Хәер, тиешле гаризасын язып, күпләр инде нәкъ шулай эшли дә.

Татарстан җитәкчелеге бөтен нәрсәдә “йомшак сәясәт” алып бара. Татарстанның мөстәкыйль дәүләтчелеген торгызу шартларында бу, бәлки, аклана дыр да. Кешенең табигате консерватив, хәтта файдалы һәм прогрессив яңалыкларга да ул авырлык белән күнегә.

“Гражданнарның 1993 елның 25 апрелендә уздачак РФ референдумында катнашу хокукын тәэмин итү турында” ТР ЮС Президиумы кабул иткән карар да тулысынча “йомшак сәясәт” рухында. Бу нәрсә миңа бик үк ошап бетмәсә дә, мин Татарстан властьларының дәлилләрен аңларга һәм кабул итәргә әзер. Белгечләр фаразлавынча, сайлаучыларның 20 проценты тирәсе референдумда катнашырга мөмкин. Ә бу бәйсез Татарстанны легитимлаштыруның (хокукларын һәм вәкаләтләрен раслауның - ред.) үзенә күрә тагын бер процедурасы. Әмма...

Суверенлыкның легитим базасын ныгыта бару белән беррәттән, без шул ук вакытта Татарстан Конституциясе һәм аның законнары белән гафу ителмәслек дәрәҗәдә тәкәллефсез эш итәбез. Әгәр дә бездә Россия референдумы үткәрелә калса, формаль-юридик күзлектән караганда бу шулай килеп чыгачак та ТР Конституциясенең 59 маддәсе Татарстан законнарын аның бөтен территориясендә өстен дип игълан итә. Димәк, Конституция бу очракта безгә референдум турында Татарстан Законына мөрәҗәгать итәргә куша. Ә анда беринди дә Россия референдумы каралмаган. Бу - беренчедән. Икенчедән, бүгенге вәзгыятьтә бу законның формаль таләпләре сакланмаган. Россия референдумын хәтта бик тә үткәрәсебез килгән сурәттә дә, безнең кулда Татарстан гражданнарыннан җыелган 180 мең култамга, яки ТР депутатларының өчтән бер өлешенең култамгасы, яки инде ТР Президентының инициативасы булырга тиеш. Ә боларның берсе дә юк. Әле бу инициативаны ТР Югары Советының зур күпчелеге яклап тавыш бирергә тиеш. Бу гына да түгел. Татарстанның референдум турында Законының 17 маддәсе буенча, референдум карар кабул ителгәннән соң бер ай узгач кына үткәрелергә тиеш. Ә монда бу шарт та бозылган. Ярый, Россиядә үз законнарына һәм Конституцияләренә тәкәллефсез карасыннар да ди. Ә без ни өчен начар үрнәккә ияреpгә тиеш? Әлбәттә, ТР Конституциясе һәм республиканың референдум турындагы Законына шушындый тәкәллефсезлекне күчеш чорына да сылтап була булуын. Әмма мин хәзерге ситуациядән файдаланып, Мәскәүнең татар суверенлыгына каршы көчләренә “ике йөрештә үк мат куярга” тәкъдим итәм. Ә нигә без, державачыларны артларына утыртыр өчен, референдумның көн тәртибенә “Сез Татарстанның дәүләт бәйсезлеген яклыйсызмы?” дигән сорауны кертмәскә тиеш? Әгәр дә без Россия бюллетеньнәрен алудан баш тартсак, иманым камил, безнең җавап империячеләрне артларына утыртырдай булачак. Әгәр дә бу сорау кертелми икән, референдумга барып йөрисе дә юк.

Тәлгать БАРИЕВ.

Алып үкенгәнче, сатып үкен

Казанның үзәк базары

Сыер ите - 800 сум
Сарык ите - 800 сум
Тавык түшкәсе - 700-2000
Йомырканың дистәсе - 150-170 сум
Эремчек - 180-200
Каймак - 400-500
Ак май - 1000
Көнбагыш маенның литры - 800
Бәрәңге - 30-40 сум
Кәбестә - 60-80
Тозлысы - 80-90
Кишер - 70-100
Чөгендер - 60-70
Суган - 80-100
Яшел суган - 200
Тозлы кыяр - 180-200
Груша - 350-450
Алма - 250-350
Бал - 2000 сум.

Укыдыгызмы, ишеттегезме...

Мәскәү. Ашыгып йөгереп барган берәү, гөнаһ шомлыгына каршы, таеп егылып башын яра да, 7 номерлы хастаханәдә җан бирә. Мәрхүмнең янында документлары булмаганлыктан, милиция аның туганнарын эзли башлый. Моның өчен мәрхүмнең бармак эзләре кирәк була. Моргта бармак эзләрен ала алмаганлыктан, мәетнең кулларын кисеп алалар да экспертизага җибәрәләр. Мәетнең туганнары табылгач, моргта алардан “мәетне тапкан өчен һәм кулларын теккән өчен” 3.300 сум каералар.

Павел Пушков страховкалау агентлыгы Ярославльнең бер кешесе белән искитмәле килешү төзегән. Әгәр дә бу кешене чит планета кешеләре урлап алып китеп, ул исән-сау әйләнеп кайтса, аңа миллион сум түләнәчәк.

- Монда берниндн дә шаяру-фәлән юк, - ди агентлык башлыгы. - Әгәр дә ул экспертизага чит планетадагылар белән булуы турында кире кагып булмаслык дәлил тапшыра алса, аңа шул минутта ук акча түләнәчәк.

Экс-президент М.Горбачевның элекке тормышыннан әлегә билгеле булмаган фактлар дөньяга чыгып кына тора. “Палея” нәшрияты мәгълүматларына караганда, дөньяга “Энциклопедия Михаила Горбачева” дигән китап чыккан. Анда элеккеге президентның мәктәптә укыганда немец телен сөймәве дә, 5 нче класстан соң мәктәпкә суынуы да, “Юный сталинец” мәктәп газетасының редакторы булуы да, Ленин рәсемен ясарга яратуы да - бар да кергән.

Италия циркларының берсеннән качкан арыслан урамда кечкенә бер малай артыннан куа башлый. Һәм алга таба нәрсә булгандыр дисез? Малайның әнисе арысланга ташлана һәм аны ерткычларча имгәтеп бетерә. Арысланның башына һәм башка җирләренә зур зыян килә. Өстәвенә әле җитмәсә ерткычның (куркудандыр инде) нервылары тәмам эштән чыга.

Таулы Карабахта әрмәннәрнең соңгы вакытта бик активлашып китүенә җавап йөзеннән, Төркия әрмәннәргә ашлык бирүне туктатачагын белдерде. Ул, килешенү буенча, Әрмәнстанга 100 мең тонна ашлык бирергә тиеш иде. Шулай да апрель башына моның яртысын инде әрмәннәр кулына тапшырганнар иде.

41 яшьлек Татарстан вице-президенты, юридик фәннәр докторы В.Лихачев Мәскәүдәге Хәлыкара информатика академиясенә гәмәли әгъза (академик) итеп сайланды. 60 тан артык фәнни хезмәт авторын БДБ дәүләтләренең зур вузларында гына түгел, Гвинея-Бисау, Мадагаскар, Болгария, Германия һәм Австрия кебек илләрнең уку йортларында да яхшы беләләр.

Казан администрациясе башлыгы 1 апрельдән 1 майга кадәр шәһәр урамнарын тәртипкә китерү айлыгы игълан иткән иде. Бу уңайдан 17 апрель көнне шәһәр буенча өмә үткәреләчәк.

Баш назирне талаганнар. Битлек киеп алган өч бик оста карак (җинаять урынында бер генә эз дә калдырмаганнар), гараж каравылчысын бәйләп, гараждан тәмәке фабрикасы директорының өр-яңа “Волга”, “УАЗ” машиналарын урлаганнар. Милли Мәҗлес премьер-министрының машиналарын эзләү эшенә иң оста белгечләр алынган.

Бу көннәрдә Казан дәүләт университетының татар халык хоры Санкт-Петербург шәһәрендә концертлар бирә. Хорда җырлаучы “Т.Я.”ның махсус хәбәрчесе Петербург хәлләрен, кайткач, үзе тулырак сөйләр.

Казанның “Рубин” футбол командасы Россия чемпионатының Беренче уенын “Металлург” (Магнитогорск) командасы белән башлап җибәрде. Казанда үткән очрашу 0:0 исәбе белән тәгәлләнде. Иртәгә казанлылар “Уралец” (Нижний Тагил) футболчыларын кабул итә.

Хәрабәләр авазы

Миргазиян ЮНЫС

Зиярәт һәм хыянәт

Адәм баласы тулысынча үлеп юкка чыкмаган шикелле, шәһәрләр дә бөтенләйгә җир йөзеннән китеп, эзсез югалмыйлар. Күмелеп калган кирпечләр, чүлмәк ватыклары гына түгел, җимерелеп юкка чыккан борынгы кала урынын каплаган туфрак, үләннәр, якын тирәдәге елга, урманнар, хәтта зәңгәр күк һәм һавада тирбәлгән тилгән кош - барысы да ниндидер бөек серне саклыйлар. Саклыйлар һәм аны теләсә кемгә генә түгел, хәтта бик нык, бик тирән кызыксынган шәхесләргә дә ачарга теләмиләр. Ни сәбәпле иң бай, иң күркәм шәһәрләрне язмыш беренче чиратта җир белән тигезләп киткән? Нилектән иң кыргый, иң кансыз-аяусыз халыклар мәдәниятькә, муллыкка ирешкән халыкларны җиңеп килгәннәр? Ә иң зур, иң гайрәтле империяләрнең җимерелеп, хурлыкка, хәерчелеккә дучар булулары? Бәлки, чыннан да, җиңү җиңелүдән куркынычрак, афәтлерәктер? Сүз сугышта, кан коюда җиңү турында бара...

Шәһри Болгар хәрабәләрен карап йөргәндә шуңа охшашлы меңләгән газаплы сораулар туктаусыз бәгырьне тырнап, тынгы бирми торды. Һәм минем күз алдымда Шәһри Болгарга кадәр күргән казылма калалар, кино тасмасындагы сурәтләргә охшап, туктаусыз җанланып тордылар. Шушы мәкаләне язарга утырыр алдыннан Троядан алып кайткан чүлмәк ватыгын, Карнактагы фиргавен сыныннан кителеп төшкән кызгылт гранит кыйпылчыгын, Акрополь, Карфаген, Бабил, Баальбек, Стоунхэд, Кносс һәм башка урыннардан алып кайткан истәлекләрне өстәлемә тезеп куйдым. Кулыма каләм алу белән аңладым - һәр кыйпылчык үз тарихын, үз фаҗигасын сөйләргә ашыга иде. Мин утыз елга якын җыйган истәлекләремне себереп алып, тиз генә яшереп куйдым. Хәзер күңел күзендәге сурәтләрне сүндерергә, оныту пәрдәсе астына яшерергә, алардан котылырга кирәк иде. ... Әнә, кайчандыр Приам патшаның сарае урынындагы кыргый груша ботагында чыпчык талпына... Ул чакта да кәҗә көтүен хәтерләткән кыбырсык турист халкы Троя казылдыкларын җан белән тоярга, шул әрнүле саф тойгы аша үз халкымның тарихына, аның әле шушы көнгә кадәр туктаусыз хыянәткә, сатылуга, сәяси алдауга юлыгып торган язмышын Троя каласының аянычлы ташлары аша күрергә комачаулаган иде. Юлдашларымны автобуска утырырга чакырдылар. Мин ялгыз калдым. Шыксыз көзге җил кыргый груша агачының ботакларын шаулатып, кырык гасыр бакый караңгылыкка чумып югалган халыкның каберлегеннән тузан куганда, минем күңел күзем алдына кинәт бер хакыйкать килеп басты: "троян аты" эченә мәкерле хыянәт тутырылган бүләк - ришвәт. Татар халкының дүрт ярым гасырга сузылган колониаль язмышы да шундый бүләкләрдән башлана һәм бүгенге көндә Татарстан белән Русия арасындагы сәясәтнең һәр микъдарында шул "троян аты" феномены бар.

... Бөтендөнья татар конгрессына җыелган кунакларны Шәһри Болгарга "метеор"ларга төяп алып килделәр. Гасырлар кимергән чал Идел ярлары. Бу елганың суына һәр гасырда кан һәм күз яше кушылган булган, ә хәзер елга суы Мәскәү ягыннан татар җиренә җимерелеп килүче империянең куркынычлы билгеләрен - экологик афәт, тынгысызлык агызып китерә. Агымга каршы, Рәсәйнең башкаласына таба татарларның җиреннән суырып алган җир җелеге - нефть, аның яланнарыннан талап алган ашлык ага. Ә Бөтендөнья татар конгрессына җыелган делегатларны алты "метеор"га төяп Шәһри Болгарны күрсәтергә илтәләр. Бу сәясәтнең акыл ачыклый алмый торган бер мистик сере дә бар кебек: 22 июнь - моннан ярты гасыр элек Алманиянең СССРга һөҗүм иткән көне. Татарстан дәүләтенең язмышы большевиклар кулында калуының бер уңай ягы да булды. Большевиклар партиясе рухиятны келгә очырып, яшәешне тоташ ГУЛАГка әйләндерсә дә, төрле җыелыш-җыеннар, конференцияләр һәм бәйрәмнәр оештыру буенча җитмеш ел эчендә бик зур тәҗрибә туплады. Конгресска җыелган делегатларның торак шартлары, ашау-эчүе, аларга күрсәтелгән якты йөз, кунакчыллык иң югары бәягә, иң зур рәхмәткә лаеклы иде. Делегатларны "сайлау" мәсьәләсе дә шактый оста хәл ителгән. Чит ил кунакларын, мәсәлән, оештыру эшенә якынрак торган үткер бәндәләр Татарстан җиренә аяк басу белән эләктереп алдылар да, партия хакимияте ысулынча тегеләр партраспределительдән алган дефицит товар рәвешендәрәк тел - үзләре, шәхси мәнфәгатьләре өчен генә үз кулларында тоттылар. Мәскәү делегациясе исә (бу инде Ельцин төзегән яңа КГБның зирәклеге!) 70-80 процентка 1992 елның мартында Татарстан референдумының келен күккә очырыр өчен Мәскәүнең Политпросвещение сараена җыелган шаһгалиләрдән тора иде. Шул кешеләр милләтнең иркле тормышы күмелгән изге җиргә зиярәт кылырга бардылар...

Бу урында Идел аеруча киң, иркен, елга ярлары диңгез ярларына охшашлы. Елга ягы бит ул суның тегә ягында, якында гына коры җир җәйрәп ятканын белдерен тора. Диңгез исә су сахрасының офыклар артына китеп югалуы турында сөйли. Ә инде океан ярлары диңгезнекеннән дә көчлерәк тойгылар - чиксезлек, кайдадыр еракта могҗизалы ят дөнья, ниндидер бай эчтәлекле, бәхетле көндәлектә яшәүче халыклар барлыгын тойдыртып, шул ераклыкларны, очраячак авырлыкларны җиңү эшенә өндәп, ярсытып тора. Болгар пристанен күрү белән кабынган беренче фикер - бу урынны диңгез белән таныш кешеләр сайлаган булырга тиеш, дигән уй булды.

Яр буенда гына ашыгыч рәвештә куелган гөмбәз астында миңа таныш түгел хәзрәт вәгазь әйтә. Сүзләре дөрес, фикере көчле мантыйкка буйсынган, шуңа карамастан, җан ул сүзләрне кабул итәргә теләми. Гарыклык чоры. Без бигрәк тә сүзләрдән гарык. Кем тарафыннан бирелгән, нинди генә вәгъдәләрнең нәтиҗәсен тикшереп карама, финал шул ук күз буяу, аерым бер сыйныфның, төркемнең, бер учлам комсызларның мәнфәгатьләрен колкындыруга кейләнгән булып чыга. Әле кичә генә партия ялганыннан ашап көн күргән туймас тамаклар, чүл бүреләре шикелле, дин тирәсенә ябырылдылар. Дөнья тарихындагы иң кыргый, әхлакый яктан иң шапшак чор - капитализмның башлап мал туплый башлаган заманы. Бүген без шундый чорда яшибез. Базар мохиты, базар кануннары күпләрнең коммунистик идеология имгәткән зәгыйфь вөҗданнарын таптап, тар-мар итеп китте. Вөҗдан саклаучылар, иманлылар өчен иң михнәтле, иң авыр заман килде.

... Ярга салган агач басмалы баскычның һәр мәйданчыгына, кулларына чәкчәк тоттырып, чибәр ханымнарны бастырып куйганнар. Болгар чорларыннан исән кала алган күркәм милли ритуал. Оештыручыларга рәхмәт әйтәсе килү кайнарланып бугазларны тырный. Ләкин тойгыларның иң сизгер, иң интим тирәнлегеннән килгән бер аваз: "Син милләтнең имин яшәгән чоры күмелгән изге җиргә зиярәт кылырга барасың, зиратка керүчеләрне чәкчәк белән каршыламыйлар..." - дип кисәтеп тора. Чәкчәккә сузылган кулның ярты юлда туктап калуын сизәм. Күңелдә зират хисе, кабер янында гына уянып китә торган әрнеткеч татлы яшәү белән үлем арасындагы пакь тетрәнү. Ниһаять, биек баскычның соңгы басмасы.

... Узурпация юлы белән "Болгар" исеменә кереп оялаган авыл аша күземне йомып узам. Күзне ачып җибәрүгә, каршымда иләһи бер киңлек. Өстә - испан күгенә охшашлы биек зәңгәр күк. Ерактагы күкшел урманнар, салмак калкулыклар артына кереп югалган иркен, ачык офык. Һәм чирәмлек. Июнь кояшыныңназлы нурлары астында яшел хәтфә чирәмлек шундый нәзберек, шундый пакь иде. Шул тоташ яшеллектән күз карашымны куптарып ала алмыйча шактый озак басып тордым. Мин бит монда беренче тапкыр, дип уйладым шул мизгелдә. Нишләп миңа шул кадәр таныш бу? Һәм исемә төште...

Мәрмәр диңгезеннән Чанаккала лиманы аша (төрекләр Дарданелл бугазын шулай атап йөртәләр) Эгей диңгезенә чыгарга алты-җиде чакрым кала Азия ярында яшел чирәм каплаган бер уйсулык ачыла. Һомерның "Илиада" эпосын укыган кеше хәтерләргә тиеш: ахейлыларның хәрби лагерьлары нәкъ шул урында була. Озак еллар Дарданелл бугазы аша узган саен мин шул уйсулыкны күзләрем талганчы карап үтә идем. Хәзер мин адәм баласының тулысынча үлмәвенә шиксез иманам. Үлемсезлекнең көчен бигрәк тә җимерелеп хәрабәгә әйләнгән борынгы шәһәрләр урынында сизәсең. Адәм баласының үлмәс җанының тәэсире, аның сулышлары, ниһаять, варисларына барып җитә алмаган җир өстендә адашып йөрүче васыятьләре кала. Аларны басып алучыларның дагалы итекләре дә, хәзинә эзләп, борынгы һәйкәлләрне җимереп йөрүче вәхшиләрнең комсызлыгы да, Рәсәй тарихында инде мең елга якын җимерү эшен җитәкләүче "күкләрдән" яуган боздан да шыксызрак бюрократлык та юкка чыгара алмый. Җимерелеп хәрабәгә әйләнгән калаларны акыл ярдәмендә, фән һәм фәлсәфә аша аңлап булмаслык атмосфера чорнап алган була, күрәсең. Шушы атмосфера тәэсирендә адәм баласының иманы кинәт айнып киткәндәй итә, комсызлык зәгыйфьләнеп кала, мал куу, өстенлеккә, хакимияткә омтылу кебек көчләр егәрен югалта, аңның аскы катламы җанланып, синең тиздән нәкъ шушы җимерелгән шәһәрдә яшәгән кешеләр тәкъдирендә җир астына керәсеңне, Мөнкир-Нәнкир каршында - барлык гөнаһларың, башка бәндәләргә төшергән җәбер-рәнҗетүләрең һәм бәхетсезләргә, ятимнәргә, гарипләргә битараф булуың өчен җавап бирәчәгеңне белгертә.

1941 елның 25 июнендә, моннан 51 ел һәм өч көн элек әтине җирләгәч, күмүчеләр зираттан чыгып киттеләр. Картлар минем ялгызымны әтиемнең мәңгелек йорты янына тезләндереп калдырдылар. Шул мизгелләрдә туган тетрәндергеч кичерешләрне укучыга җиткерерлек сүз таба алмыйм мин. Менә әле дә, Шәһри Болгар хәрабәләре каршында басып торганда, җанымны нәкъ шул әтием кабере янындагы төсле утлы тойгылар айкый иде. Бәлки бу - үзен татар милләте вәкиле итеп тойган һәр шәхес өчен уртак кичерештер? Чөнки һәр татар кешесенең узган һәм киләчәк язмышы шушы ташларга килеп тоташа. Безнең ерак бабаларыбызның иминиректә яшәгән чорлары шушы ташлар астына күмелгән, һәм әгәр без бүгенге азатлык көрәшендә бердәмлеккә ирешә алмыйча, үзара ызгышып, милли мәнфәгатьне дошман кулыннан алган ришвәтләргә алыштыруыбызны дәвам итсәк, киләчәк өметләребез дә хәрабәләр астында калачак.

(Дәвамы бар.)

Үз башыннан кичкән белә

«Русский» тәртипләре, яки Минотаврны кем җиңәр?

Минем күңелгә ерак җәһәннәм кебек кереп калган "Русский утравы" дигән атама соңгы вакытларда төрле мәгълүмат чараларында еш кабатлана башлады. Ниһаять, "хәбәрдарлык", "закон", "дөреслек" дигән төшенчәләр шушы зур булмаган "ябык" утрауга да барып җиткән икән. Ничек алай булган бу? Югыйсә, бу җәһәннәм утравының корбаннары бер елны да быелгыдан азрак булмый иде бит (әле без анда вакытта снаряд ташыганда егермеләп матросның снаряд базаларында һәлак булуы турында да ишетелде). Күрәсең, рәнҗетелгән аналарның һәм аларның балаларының каргышы бер төшмичә калмыйдыр. Әмма... Русский утравындагы хәлләрнең якын киләчәктә яхшыга үзгәрәчәгенә мин барыбер ышанмыйм. Чөнки Русский утравындагы хәрби хезмәтнең бөтен атмосферасы, андагы тормыш рәвеше кешенең асылына каршы юнәлдерелгән. Бу утрау ГУЛАГның исән калган бер кисәкчәсе булып тоела миңа. Монда Русия империясе рухы. Яңа җирләрне яулап алу мөмкинлеге беткәч, агрессиясен кая куярга белмәгән бу өрәк үз балаларын үзе ашый башлаган төсле.

Владивостоктан ерак түгел Япон диңгезендә урнашкан бу михнәт утравы... Утрауның буеннан-буена - кемнәр төзегәне дә онытылган (японнармы, урысламы?) дотлар, җир асты юллары... XIX гасырларда төзелгән "кирмән" - казармалар... Аларда хәрби укуларга дип җибәрелгән матрослар яши. Тәрәзәләре тимер рәшәткәле бу казармалар эчтән дә, тышкы яктан да төрмәне хәтерләтә. Казарма эче өчар яруслы караватлар белән дыңгычлап тутырылган. Офицерлар монда бик сирәк күренә: алар я матрослар авызыннан тартып алынган ризык исәбенә үз шәһәрчекләрендә күңел ачып яталар, яисә балык тотарга китәләр - азмыни алар өчен күңелле эшләр?!

Казармада тәүлекнең 24 сәгате буена тавыш, гауга. Кыскасы, чын җүләрләр йорты, ягъни, хәзергечә әйтсәк, "дурдом". Старшина булып калып "картайган", дурдом тормышыннан шешенеп беткән дембельләр чагыштырмача иркен - Ленин бүлмәсендә ял итәләр, самогон куалар, "романтик хәрби хезмәтләре" турында альбом әзерлиләр... Әле тагын тәбәнәк чорма бар: анда үзе өчен ныклап көрәшә алмаган берәүнең сөлге белән мыегын кыралар, яисә кешелек дәрәҗәсен соңгы чиккә кадәр төшереп, башкача, тагын да аяусызрак, кабахәтрәк мыскыл итәләр... Барысын да сөйләп бетереп буламыни?!

Йоклаганда матрослар киемнәрен я киеп, я мендәр астына яшереп йоклый. Яңа кием бирмиләр, шуңа күрә трусигыңны салып куйсаң, аны да урлаячаклар төнлә.

Тагын да "көлке" һәм авыр хисләр уятучы эпизодлар искә төшә... Мәсәлән, камбузга (ашханәгә) керү: команда булуга, барлык кеше сугыша-төртешә нәни генә ишектән эчкә ыргыла. Килеп керүгә, кашык-фәлән дә тотып тормыйча, кем нәрсә эләктерергә өлгерә, шуны я авызына, я кесәсенә тутыра... Билгеле, бер-ике секунд ишектә тоткарланганнар ач кала...

Хәрби укулар ничек бара соң? Мәгънәсез, кирәге булмаган кара эш эшләп... Хәтерлим әле: без ике ай буе бер зур гына торбаны җир астына биш тапкыр казып күмдек һәм биш тапкыр кире казып чыгардык. Ни өчен? - "У матросов нет вопросов". Күрәсең, бу - дәү корсаклы, адым саен тукталып хәл алучы офицерларның "салага" матросларга "хәрби белем" бирүе булгандыр.

Без килгәнче, Брежнев-Андропов заманнарында, Русский утравында плацны лом белән себергәннәр, тәрәзәләрне дә лом белән юа торган булганнар... Матрослар түзә алмыйча ачлык игълан иткәч, бу Мәскәүгә ишетелгән, һәм матросларны өйләренә (?) кайтарып җибәргәннәр дип сөйләделәр.

"Кто видел остров Русский - тому не страшен Бухенвальд", - диләр иде. Хәтерлим әле: һәр матросның диярлек башында бер генә уй иде: бу мәхшәрдән ничек качарга? Чөнки күп матросның палач та, кол да буласылары килми, ә гомуми атмосфера икенең берсен сайларга этәрә иде... Син кол булмас өчен кемнедер кыйнарга, аңа туктаусыз кабахәтлек эшләргә тиешсең. Нейтраль гына булып калу мөмкин түгел диярлек. Шуңа күрә качарга омтылучылар да, үзләрендә төрле авыру китереп чыгаручылар да, үз-үзенә кул салырга омтылучылар да булды.

Мәгънәсезлек, хайванилыкка төшү, кешелек сыйфатларын югалта бару, рухи гариплек - менә нәрсә хас иде Русский утравындагы хәрби тормышка. Бу утраудагы хәрби тормыш кешенең асылына каршы, димәк, Аллага каршы да эшләнгән җинаять, минемчә.

Нәрсә бәйли соң Татарстанны Русский утравы белән? (Белмим, хәзер җибәрәләр микән Татарстаннан бу утраута?) Алда куелган сорау белән бәйле рәвештә, минем күңелдә яшь, сылу кызлар белән тукланучы һәм һаман корбаннар сорап үкерүче Минотавр образы гәүдәләнә. Хәтерлисезме Крит утравында яшәүче үгез башлы, кеше гәүдәле албасты турындагы мәгълүм грек мифын? Русский утравында яшәүче "хәрби минотавр"га яшь егетләр белән, аларның сәламәт тәне, рухы, әхлагы белән түли Татар иле...

Уйланып карыйк... Әйе, Русский ише утраулардан гына тормый Русия армиясе. Әмма шул ук вакытта, "русскийутраулылык", гомумән, Русия армиясенә хас күренеш. Мондый "хәрби тормыш" егетләрдән чын ир түгел, ә хайвани хисләр белән яшәүче түбән зат ясый. Бу бары тик югалган сәламәтлек, сынган рух, сүнгән сәләтләр... Бәлки ул төрмә тормышы өчен иммунитет тудырадыр, әмма армия шуның өченме?!...

Русский утравында матросларның күпләп һәлак булуы турында җәмәгатьчелеккә ниһаять ирешкән хәбәрләр Русиянең "хәрби минотаврына" Татарстанның яшь егетләр белән ясак түләүдән туктарга тиешлеген тагын бер кат искәртә кебек...

Минемчә, "сакчы" сүзенә аның сәламәт мәгънәсе кайтарылырга тиеш: татар егетләре, беренче чиратта, империя чикләрен түгел, ә үз халкын, үз милләтенең мәнфәгатьләрен сакларга, якларга өйрәнсеннәр иде. Бары шул чакта гына алар чын ирлар булыр һәм, бәлки, татарларның югалган кыюлыгы, горурлыгы да кире кайтыр иде. Ә милләт, халык үз балаларын яклый белсен иде!

Илдус НУРУЛЛИН.



СЕРДӘШ

"Сердәш"кә исемләнгән хатлар әле дә булса бихисап. Хәтта бүген, кеше хатлар язудан бизеп килгән заманда да. Менә синең алда хат - анда үзенчәлекле бер язмыш яисә гаҗәеп кызыклы бер хатирә. Әйтерсең лә, шушы иксезчиксез тормышның бер кисәкчеге хат белән синең күз алдыңнан үтә. Кабатланмас матур бер җыр кебек, нихәтле нәзакатлелек, самими хисләр... Үзең генә укып хозурлану җитми, ирексездән башкаларга да белдертәсе килә ул хисләрне.Шуңадыр ахры, "Сердәш"тә басылган бер генә язма да күңел кылларын тибрәтми калмый. Яшьлектәге саф мәхәббәт турында хикәятме ул, сабый чакның онытылмас бер хатирәсен искә төшерүме, үзең белән үзең сөйләшүме - бөтенесен- җиһанда мең кеше бар икән, мең төрле кичерә торгандыр. Шуңа да ул хисләр гадәти була алмый. Аларның һәркайсы - кабатланмас бер дөнья. Уйландырырлык, күңелеңдә игелекле хисләр тудырырлык, елатырлык, җырлатырлык, тетрәндерерлек, нәфрәтләндерерлек, ярдәмгә ташландырырлык язмалары белән "Сердәш"нең даими яшәве, еш чыгып торуы сездән дә тора, кадерле дуслар. Языгыз! Ә бүген сезнең хөкемгә - берничә язмыш. Укыгыз, уйланыгыз.

Рина ЗАРИПОВА.

Гомер буе көтәчәкмен...

Сиңа ялгызлыктан гаҗизләнгән, йөрәге, күңеле тулы уйларны кемгә бушатып тынычланырга белмәгән бер кыз яза. Бәлки син мине аңларсың.

Синдә басылган хатларны даими укып барам. Ике юл чатында кая барып, кемгә егылырга белмичә аптырап калганнарның берсе мин...

Миңа 19 яшь. Бөтенесе алда. Ә арттагысы?.. Искә төшерергә дә чирканам.

Без аның белән көз көне, коеп яңгыр яуган кичне таныштык. Машинада эшли иде, Казанда. Мин алар авылына иптәш кызым белән кунакка кайткан идем. Мин ул вакытта Казанда педучилищеда укый идем. Миңа - 18, ә аңа 26 яшь. Яраттым мин аны, бер күрүдә үк яраттым. Моңа кадәр юньләп егетләр белән йөрмәдем, ә аны күрүгә миндә ниндидер хис уянды - мәхәббәт дигәннәре шулдыр инде.

Минем янга ул Казанда да гел килеп йөрде, авылларына да бик еш кайта идем. Әйе, аның өчен генә кайта идем.

Аның әйткән сүзләре колагымда әле дә яңгырап тора: "Нишләттең син мине, нишләттең? Минем болай озак итеп берәү белән дә йөргәнем юк иде", "Курыкма, тимим мин сиңа. Үзең "мә" дисәң дә тимим. Мин кызларның гомерләре буе мине каргап яшәүләрен теләмим". Тик ул сүзендә тормады. Ә аннары, билгеле инде, минем янына килми башлады. Шуннан соң миндә мондый уй туды: китәргә бу дөньядан - бары шулай эшләсәм генә мин бөтен нәрсәдән котыла алам. Башка юл юк. Кешеләрдән ишетеп мин үтерү көченә ия булган дару таптым. Ул даруны бер дә үземнән калдырмый идем.

Бер кайтканымда ул бер кунак кыз белән клубка керде. Бераз утырганнан соң алар чыгып киттеләр. Ә минем башка чыдар хәлем калмаган иде, теге даруымны учлап-учлап эчтем. Ачуым басылды. Кайтканда барысы белән дә саубуллаштым, үлүемә шигем юк иде. Мине районга сырхауханәгә илткәннәр, аннары Казанга алып киткәннәр. Аңсыз килеш 5 көн яттым. Аңыма килгәндә реанимация бүлегендә идем. Әниемә дә хәбәр иткәннәр. Табиблар нәрсә булганны барысын да белделәр. Әнигә дә әйткәннәр. Әнием мине сукмады да, орышмады да, чөнки инде бөтен эш узган, орышып кенә бер нәрсәне дә кире кайтарып булмый иде.

Шифаханәдә бер ай яттым. Һәр көн саен Ул килер дип өмет иттем. Ләкин Ул килмәде. Казанда булып та килмәде.

Инде юллар аерылган, укып бетереп эшли идем. Менә мин тагын алар авылында. Ләкин бу юлы мин Аның янына түгел, ә якын дустымны сагынып кайттым.

Һәм менә без тагын бергә - Ул тагын килде. Чөнки ул көнне башка кунак кызлар юк иде. Ә үз авыл кызлары белән Ул йөрми. Үтенечен кире каккач, Ул минем яныма башка килмәячәген әйтте. Ә мин, горурлыгымны саклап, көлдем генә. Синнән башкалар да бетмәс әле, дидем. Ә үземнең эчемдә ут иде. Шуннан бирле мин Аны күргәнем юк. Һәм күрмәячәкмен дә. Ә ничек чыдармын - белмим. Бәлки бөтен нәрсәдән котылуның тагын шул юлын сайлармын. Ләкин инде бу юлы кешедән еракта, чөнки тагын алып калулары бар. Аңа кирәк булмаганны, башка кемгә хаҗәт соң мин? Әгәр кемгә дә булса кияүгә чыга калсам да, хәзер бит миңа бер кеше дә якты чырай күрсәтмәячәк. Кемгә нәрсә әйтсәм дә: "Син йөргәнсең бит әле, ә миңа ярамыймы?" - дип кенә әйтәчәкләр.

Менә дүрт ай инде күзләремдә яшь кипкәне юк. Ләкин берәүгә дә кирәк түгел минем күз яшьләрем. Мин аны барыбер яратам. Кайчан килсә дә, мин аны кире борып җибәрә алмаячакмын, беркайчан да. Башка кеше белән йөрергә теләмим дә. Гомерем буена Аны көтәчәкмен, килмәсен белсәм дә, барыбер көтәчәкмен. Бәлки юлда очрар, кем белә. Тормыш сукмаклары бит алар әллә кайларга китереп чыгара. Бәлки әле үзе миңа килеп ялынып. Мине үзенең башыннан шундый хәлләр узган кеше генә аңлый алачак. Ә аңламаганнар, зинһар, мине сукмагыз, иң якын дустым "Сердәш"кә язмагач, кемгә генә сөйлим соң бу сүзләремне?

Сезгә ихтирам белән, ГҮЗӘЛ.
Аксубай районы.

Мең йөрәктә мең төрле хис

Балалыктан чыга алмыйм

Хаклыдырмы мин, түгелме, әмма кайчагында дөньяда яшәргәме, юкмы дип еш уйланам. Нигә? Кем өчен? Нинди максат белән? Уйлап карасаң, без беркемгә дә кирәк түгел бит. Беркемгә дә. Без шөгыльләнгән, без эшләгән бөтен нәрсә - гадәтләнү генә бит ул. Ияләшү. Шул гадәт буыннан-буынга күчә бара. Менә мин үземне шул гадәтләр, йолалар кысасына һич кенә дә кертә алмыйм инде. Берничек тә. Берәүгә дә охшыйсым килми минем. Минем шәхес буласым килә. Ләкин булдыра алмыйм. Ә тирә-юньдә мине аңлаучы зат юк. Хәтта тудырып үстергән әти-әнием, серләшеп бергә тәгәрәп үскән апа-сеңелләрем дә аңлый алмый мине. Дөрес, мин күңелемдәгесен аларга ачып салмыйм да. Ә кеше күңеле карурман бит ул. Шәм белән яктыртсаң да, син андагы хәлләрне күрә алмыйсың. Ә бит мин йомыкыйлардан түгел идем. Күңелемдәге хисләрне уртаклашасым килеп, күпләргә мөрәҗәгать иткәнем булды. Тик аңлата алмадым. Мине алдадылар гына.

Үзем-үзем хәйран калам. 25 яшемә җиттем, әле үземне бәхетле хис иткәнем булмады. Әллә нинди кеше мин. Гел уңышсызлыкка очрап торам. Чәчәк үстерүче буласым килде. Әти-әни рөхсәт итмәде. Фармацевт бул диделәр, шуңа укып йөрим. Тик миннән фармацевт чыкмаячак. Бер егетне үлеп яраттым, ул кире какты. Икенчене сөйдем, анысы мине алдап китте. Нигә мине язмыш гел алдый соң? Бәлки мин чынбарлыкны кабул итә алмыймдыр? Егетләрдән миңа дуслыктан башка берни кирәкми. Тормыштан мин олы хисләр өмет итәм. Кибеттәге чиратларны мин аңлый алмыйм. Сүгенүләрне мин күтәрә алмыйм. Гаҗәпкә калам, егетләр нигә хатын-кызның эчке дөньясына түгел, тәненә генә кызыга икән? Ә бит күңел дигәне миндә бик нечкә. Мине күкләргә күтәрү өчен дә, җиргә егып төшерү өчен дә бер сүз җитә. Нәкъ балалар кебек беркатлы мин. Ә бәлки мин һаман да баладыр? Буй-сыным гына үскән, ә күңелем белән мин әле дә бала-чага. Китапларда тормыш гел бүтәнчә. Бүтән төсмердә. Анда рухи дөнья, эчке матурлык турында язалар. Дөрес, мин дә аңа ышанам. Ләкин дөньяда чирек гасыр яшәп, бер генә нур тамчысы да очратканым юк әле.

ЛИЗА.
Пермь.

Күңелем тулы изге хисләр

Бөтен дөньяга даны таралган Мексика актрисасы Вероника Кастро уйнаган фильм мине нык үзгәртте. Уйландырды. Бу хатын акылдан язган икән дип уйлый күрмәгез. Мин үз акылымда. Миңа 35 яшь. Ирем, өч улым (15,13,8 яшьлекләр) бар. Ирем механизатор, үзем тади хезмәт кешесе. Әйбәт кенә яшибез. Тормышыбыз уртача. Миңа бер яшь тулганда әтием белән әнием аерылышалар. Әти үзе белән бергә укыган апага өйләнеп Казанга китә. Алар икесе дә табиблар. Ә әнием Төмән өлкәсенә китә. Мин ятим бала булып фәтир хуҗасында калам. Тәрбия кылган әти-әнием бик әйбәт кешеләр. Алар миңа яхшы тәрбия бирделәр, укыттылар.

Беренче тапкыр үз әниемне 14 яшемдә күрдем. Ул безгә кунак апа булып килде. Миңа яхшы киемнәр, күп итеп акча бирде. Елый-елый иркәләде. Бик матур минем әни, зур түрәгә иргә чыккан, балалары юк. Икенче тапкыр кияүгә чыкканда күрдем. Ләкин ул чакта миңа аның әнием икәнлеген әйтмәделәр. Ул мине алып китәргә теләде, ләкин минем кунак апага ияреп китәсем килмәде. Әнием икәнен ул вакытта ук белгән булсамчы! Хәзер ул юк инде, операциядән вафат булган. Ә әтием исән, Уфада яши, танылган табиб. Ләкин мин алар белән очрашканым юк. Мин бер гади авыл хатыны, татар кызы. Тәрбия кылган әтием инде үлде, әнием исән, безнең белән яши. 83 яшьтә. Каенанам да безнең белән. Бик тату яшиләр. Алар изгеләр, кадерле кешеләребез. Без аларны бик нык хөрмәтлибез. "Байлар да елый" дигән фильмны карый башлагач, мин гел икенче кешегә әйләндем. Төшләремә әнием керә. Күңелемнән мин Вероникага хат язам. Сезгә бер үтенечем бар: арагызда бернинди туганы булмаган ятим сеңел яки апа булса, мин танышыр идем, ярдәм итәр идем. Без авыл кешеләре бит, гади дә, намуслы да. Авылда бәрәңгесе, ите, мае бар, ирем әйбәт кеше.

Сәлам белән, НУРИЯ.
(Адресым редакциядә)

"Сердәш" киңәшләре

- Икмәк яхшы саклансын өчен аны берничә җире тишелгән полиэтилен капчыкка салып куегыз.
- Майлы савыт-сабаны аш серкәсе кушылган суда юу бик уңайлы.
- Кесәдәге ачкыч бәйләме шалтырап йөрмәсен дисәгез, ачкыч араларына кечкенә магнит куегыз.
- Тәрәзә рамнарын буяр алдыннан кулыгызны сабын белән ышкыгыз. Шулай эшләгәндә, кулга йоккан буяу таплары тиз юыла.

Сәхнәгә чыгар алдыннан.
Е.КАНАЕВ фотосы.

Илгиз ХӨСНУЛЛИН

Ядкарь

Хатын-кызның күз яше керфек очында.
(Әнием сүзләре).

Унбиш яшьтән киттем олы юлга,
Юлдаш булды синең йөз аклыгың.
Елап калдың. Табигыйдер, аңлыйм,
Хатын-кызның күңел йомшаклыгын.

Ул көн иста: кар җемелди иде,
Карны тишеп, яшең тамды җиргә.
Киләчәккә аяк баскан мәлдә
Шул суратне алдым хәтеремә...

Юллар йөртте мине төрле якта,
Өермәсен кичтем, җил - давылын,
Давыл эчендә дә онытмадым
Әнкәм күз яшьләрен, әнкәм кулын.

Юл тузаны, еллар томанына
Уралды да калды яшьлек язы.
Бер ядкаре һич тә югалмады:
Туң туфракта гөлләр үстерердәй
Анам күз яшьләре, анам назы.

* * *

Барысы да әйбәт, җитеш кебек -
Улым китә таңнан укуга.
Кызым торып аваз салу белән
Ямь өстәлә тагын йортыма.

Барысы да болай матур кебек -
Ап-ак кардан дөнья киенә.
Тәрәз карнизендә, язны көтеп,
Күгәрченнәр гөрли, сөенә...

Тирә-юньдә гүя бәхет кенә...
Исем китеп карап торамын.
Куенымнан иомлы кәгазь алып,
Укымыйча кире куямын.

Мөмкин түгел мондый хәл булуы!
Кая куйыйм икән бу җанны?
Китеп бардың, ватып урталайга,
Икәү төзеп кергән җиһанны..

КОТЛЫЙБЫЗ!

* * *

Арча районы, Иске Чуриле авылында яшәүче әтиебез Равил һәм әниебез Әнзия Хәлиловаларга 60 яшь тулды. Аларны чын күңелдән кайнар котлыйбыз, озын гомер, корычтай нык сәламәтлек, ак бәхетләр, тыныч, тигез тормыш, балаларының һәм оныкларының игелеген күреп, озак яшәүләрен телибез.

Иң изге теләкләр белән: улыгыз, киленегез һәм оныкларыгыз.

* * *

Әлки районы, Түбән Әлки авылында яшәүче әтиебез Җәмил белән әниебез Мәмдүдә Сиражиеваларга 63 яшь, ә бергә тормыш итә башлауларына 40 ел тулды. Кадерле әтиебез, әниебез! Сезне олы бәйрәмегез белән чын күңелебездән котлыйбыз, кояштай озын гомер, кайгы-хәсрәтсез, шатлык белән бергә-бергә тату, балаларыгызның игелеген күреп гомер итүегезне телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызларыгыз, кияүләрегез, киленегез һәм оныкларыгыз.

* * *

Сарман районы, Саклаубаш авылында яшәүче әтиебез Рәфгать Хәйбрахмановка 65 яшь тулды. Кадерле әтиебез! Сине чын күңелебездән юбилеең белән котлыйбыз, матур тормыш, гаилә бәхете телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызларың, кияүләрең, оныкларың.

* * *

Балтач районы, Балтач авылында яшәүче әнием Тәскирә Галимҗановага 40 яшь тулды. Әниемне олы бәйрәме белән чын күңелемнән котлыйм. Аңа киләчәк тормышында кояштай озын гомер, корычтай нык сәламәтлек, шомырт чәчәгедәй ак бәхет, тыныч тормыш, шатлык теләп калам.

Изге теләкләр белән: Благовещенск шәһәрендә хезмәт итүче улы Рамил.

* * *

Татарстанның Лениногорск районы, Керкәле авылында яшәүче кадерле әнием Роза Ялаковага 67 яшь тулды. Әнием, сине чын күңелдән туган көнең белән тәбрик итәм. Гомерең озын, аяк-кулларың сызлаусыз булсын Әни.

Улың Ильяс.

* * *

Әлки районы, Иске Салман авылында яшәүче әниебез Зәйтүнә Нуруллинага 55 яшь тулды. Кадерле әниебез! Бу олы бәйрәмең белән тәбрикләп, сиңа матур тормыш, җан тынычлыгы, күңел көрлеге, гаилә бәхете, киләчәк тормышыңда уңышлар юлдаш булуын телибез. Һәрвакыт шат күңелле, сау-сәламәт бул, кайгы-хәсрәт күрмичә озын гомер кичер!

Изге теләкләр теләп: уларың, киленнәрең, оныкларың исеменнән, кызың Земфира.

ҮЗ ТИҢЕМНЕ КӨТӘМ

Укучыларыбыз игътибарына!

Танышу хезмәтеннән файдалану бәяләре 1 апрельдән үзгәрде.

Газетада танышу турында белдерү бастырып чыгару өчен редакция счетына 500 сум, "номер"га хат язган өчен 200 сум күләмендә акча күчерергә һәм акча күчергәнлек турындагы квитанция белән хатны редакция адресына җибәрергә кирәк. Редакция "номер"ларга хатларны үзе тапшыра, ләкин аларның җавап хаты язуларын гарантияләми һәм адресларын хәбәр итми. Акча күчерү турында квитанциясе булмаган танышу хатлары газетада басылмый һәм "номер"ларга тапшырылмый.

* * *

ЗМ-536

Миңа 37 яшь. Авыл җирендә яшим һәм эшлим. Бер хроник авыру кичерәм. Ирем авариядә һәлак булды. Үзем уртача буйлы, тулы гәүдәле, сабыр холыклы, авырлыкларны үз өстемә алудан курыкмыйм, ярдәмчел, бик уйчан, бик моңсу, йомшак күңелле. Авылдан күченеп китә алмыйм. Йорт-җирем, каралты-курам бик яхшы. Яшәр өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Минем янга килеп яшәргә риза булган, тормышны алып барырлык, ышанычлы, төрмәдә утырмаган, аракы эчми торган, буе кимендә 170 см булган ир-егеттән хат көтәм. Минем белән бәйләнәсе кешенең анисе, әбисе яки апасы булса иде. Җитди итеп язылган, фотосурәтләр салынган хатларга җавап бирәм.

МН-538

Миңа 21 яшь, буем 160 см. Авылда туып-үскән, кияүдә булмаган татар кызы. Хәзерге көндә шәһәрдә яшим. Урта белемле, йортта хатын-кыз башкара торган барлык эшләрне дә яратып башкарам. Аракы эчү белән мавыкмаган, нык гаилә корырга теләге булган 21-26 яшьләрдәге, авылда яшәүче ир-егет белән танышырга телим. Хат язучылар фоторәсемнәрен дә җибәрсеннәр иде, аларны кире кайтарам.

АЛ-540

Миңа 36 яшь, буем 164 см. Югары белемле. Шәһәрдә яшим. Минем кебек ялгызлыктан туйган, 34-40 яшьләрдәге, буе кимендә 170 см булган ир-егет белән гаилә корырга телим. Әлмәт шәһәреннән яки якын районнардан булса, бигрәк әйбәт.

ФИ-691

Миңа 31 яшь, буем 182 см. II группа инвалид. Аракы эчмим. Музыка яратам. Совхозда эшлим. 25-33 яшьләрдәге кыздан фотосы салынган хат көтәм.

БИ-693

Миңа 30 яшь, буем 165 см. Милләтем татар, урта белемле. Авылда туып-үстем, шунда яшим һәм механизатор булып эшлим. Аракы эчү белән мавыкмыйм, тәмәке тартмыйм. Физик кимчелекләрем юк. Үзем тыныч холыклы, эш яратучан. Авылда туып-үскән, 25 яшьтән артмаган татар кызы белән танышырга телим. Фотосурәте салынган хат көтәм.

ГР-695

Миңа 29 яшь, буем 170 см. Авылда туып-үстем, өйләнмәгән татар егете. Урта белемле. Йөз-кыяфәтем уртача. Колхозда эшлим. Тәмәке тартмыйм, аракы эчмим, аз сүзле, начар гадәтләрем юк. Хуҗалык эшләрен яратып башкарам. Буш вакытларымда укырга, музыка тыңларга яратам. 24-32 яшьләрдәге, эшчән, сабыр холыклы, кешеләргә хөрмәт белән карый белгән, ныклы гаилә корып, авыл җирендә яшәргә риза булган, балалар яратучан татар кызы яки хатын-кыз белән бик теләп гаилә корыр идем. 1 кыз баласы булса да ярый. Хат язучылар Казаннан яки якын-тирә районнардан булса, бигрәк әйбәт. Килгән фоторәсемнәрне кире кайтарам.

ЗР-697

Миңа 34 яшь, буем 170 см. Милләтем татар, өйләнгәнем булмады. Авылда туып-үстем, хәзер шәһәрдә яшим. Гаилә кору өчен, үземә тиң булырдай 30-35 яшьләрдәге татар хатын-кызы белән танышырга телим. Кечерәк яшьтәге баласы булса да ярый.

ГХ-699

Миңа 75 яшь. Авылда үз йорт-җирем белән яшим. Хатыным вафат булды. Аракы эчү белән мавыкмыйм. 65-70 яшьләрдәге берәр ялгыз карчык хат язса, бик шат булыр идем. Бер-беребезгә терәк булып, соңгы көннәребезне бәхетле итеп яшисе иде. Ялгыз тормыш итүләре бик авыр. Хат язучы Чүпрәле, Тәтеш, Буа районнарыннан булса, бигрәк әйбәт.

ИК-701

Мин 29 яшьлек татар малае. Буем 175 см. Өйләнгән идем, законлы аерылышкан. Колхозда механизатор булып эшлим. Үз фатирым бар, мал-туар асрыйм. Тик хатын-кыздан бәхет булмады. Бәлки, минем кебек ялгызлыктан туйган, гаилә корырга теләге булган берәр хатын-кыз җавап бирер. Баласы булса да ярый. Фотосурәт кирәкми, миңа йөз матурлыгы түгел, җан матурлыгы мөһим.

ХР-703

24 яшьлек, буе 174 см булган, сау-сәламәт, сөйкемле, бер тапкыр да өйләнеп карамаган, авылда яшәүче һәм яшәячәк татар егете үз тиңен табарга теләли. Фотосурәтләр белән килгән хатларга җавап бирәм.

ГФ-705

Миңа 40 яшь, уртача тазалыкта. Авылда яшим, колхозда механизатор булып эшлим. Хатыным белән законлы аерылыштым. Милләтем татар. Кулымнан барлык эш тә килә. Аракы эчмим, тәмәке тартмыйм. Авыр вакытта таяныч булырлык, ике ир баланы канат астына алырлык, авыл җирендә яшәргә теләүче хатын-кыз белән танышырга телим. Бер яки ике баласы булса да ярый.

ГГ-542

Миңа 34 яшь, буем 160 см. Урта белемле, кияүдә булмадым. Авылда туып-үстем, хәзер Казанда тулай торакта яшим. "Арыслан" йолдызлыгы астында туганмын, сау-сәламәт. Тәртипле гаилә корырга теләүче, начар гадәтләре булмаган, аракы эчү белән мавыкмаган, ышанычлы, өйләнмәгән татар егете яки тол калган, бер баласы булган ирдән хат көтәм. Килгән фоторәсемнәрне кире кайтарам.

МЛ-544

Миңа 24 яшь, буем 166 см. Уртача тазалыкта, яшел күзле, төскә-биткә зарланырлык түгел. Зодиак билгем - "Кысла". Әлеге вакытта авылда яшим һәм эшлим. Ирем белән законлы аерылыштык. 4 яшьлек улым бар. Үзем сабыр, йомшак күңелле. Буш вакытларда бәйләргә, музыка тыңларга яратам. Балалар яратучы, тыныч холыклы, аракы эчү белән мавыкмаган, 25-32 яшьләрдәге, буе кимендә 170 см булган ир-ат белән танышыр идем. Бер баласы булса да ярый. Килгән фотосурәтләрне кире кайтарам.

ЮИ-546

Мин күп ел буе тол хатын. 39 яшь, буем 160 см. Төскә-биткә яшьрәк күренәм. Сабыр холыклы. Аракы эчмим, тәмәке тартмыйм, сәламәт тормыш алып барам. 18 һәм 14 яшьлек улларым бар. "Үгезбозау" йолдызлыгы астында туганмын. Булачак тормыш иптәшем дә аракы белән артык мавыкмаган, тормышка аек акыл белән караган, безне ихтирам иткән, эш сөйгән, төрмәдә утырмаган 38-45 яшьләрдәге ир-ат булса иде. Бер баласы булса да ярый. Хатта фоторәсем булу шарт.

ХР-548

Миңа 35 яшь, буем 154 см, уртача гәүдәле. Ике балам белән Яр Чаллы шәһәрендә яшим. Ялганны, икейөзлелекне, хыянәтне кичерә алмыйм. 35-45 яшьләрдәге, озын буйлы, гәүдәсе чамасыз тулы булмаган, сабыр холыклы, киң күңелле, аракы эчү белән мавыкмаган ир-ат белән танышыр идем. Хат язучылар фоторәсемнәрен дә җибәрсеннәр иде, аларны кире кайтарам.

ВИ-707

Миңа 38 яшь. Уртача буйлы. Аракы эчмим, тәмәке тартмыйм, ләкин бер кимчелегем бар - күзлек киям. Авылда үз йортымда яшим, мал-туар асрыйм. Клубта мөдир булып эшлим. Бер эштән дә курыкмыйм. Минем янга күчеп килергә риза булган, үземнең яшьләрдәге кыз яки тол хатын белән танышыр идем.

СА-550

Мин 21 яшьлек татар кызы. Буем 162 см. Волгоград өлкәсендә яшим. Матур йөзле. 21-25 яшьләрдәге егет белән танышырга телим. Фоторәсем салынган хатлар көтәм, аларны кире кайтарам.

ФФ-709

Миңа 27 яшь. Тормыш корып, бәхетле яшисе урынга, яшьлегемне ялгыз тилмереп үткәрәм. Көннәр бер-бер артлы үтеп тора, ә сөйгән кешемне таба алмыйм. Бәлки, төскә-биткә матур булган, 20-25 яшьләрдәге кыз хат язар. Мин үзем шәһәрдә яшим, үз фатирым бар, спорт белән шөгыльләнергә яратам.

СФ-552

Мин бер ялгызым гына калдым. Бик күңелсез. Кызым бар, тик ул минем белән яшәми. Миңа 43 яшь, буем 155 см. Махсус урта белемле. Сабыр холыклы, сөйкемле, йомшак күңелле татар хатыны. Казан шәһәрендә яшим. Җыр тыңларга, татар театрларына йөрергә яратам. Күңел төшенкелегенә бирелмим. Сабыр холыклы, игелекле, тырыш, эшчән, азмый-тузмый торган, 45-55 яшьләрдәге мөселман ир-атыннан хат көтәм

Фараз

Ул уен гына түгел, ә укучыларыбызның "Т.Я." турында ниләр уйлавын ачыклау да

Мин яратып укыган газетабызның тиражы 342.000 булыр дип уйлыйм, ә әнием 200.000 дип фараз итә. Әти исә - 280.000, ә апам 495.000 булыр дигән фикердә. "Татарстан яшьләре" бик-бик яхшы газета.

Сәлам белән, РЕЗЕДА.
Башкортостанның Бакалы районы, Наратлы авылы.

* * *

"Татарстан яшьләре"н бик күп еллардан бирле алам һәм бик яратып укыйм. Тырышуыгыз өчен рәхмәт. Киләсе ярты елга аның тиражы, минем уйлавымча, 300.000гә җитәр. Ә минем 11 яшьлек улым Радик 250.000гә җитәр ди.

Сезгә зур рәхмәтләр белән, өч бала анасы ЗИЛӘ.

Сания апа өшкергәләп җибәрсә, тираж күбрәк тә булыр.

Түбән Кама.

* * *

Киләсе ярты еллыкта "Татарстан яшьләре"нең тиражы 250.000 булыр дип уйлыйм. Ә безнең гаилә 300.000 булыр дип фараз итә. Хакыннан тормыйбыз. Чөнки 200 сум ул хәзер 20 сумга да тормый. 20 сумга, ачуым да килмәгәе, бер ипи дә алып булмый бит. Ә "Татарстан яшьләре" шундый шәп, эчтәлекле. Газетаны алдырмасаң, ул акчаны нишләтәсең? Башка газетаны алмасам да, мин "Татарстан яшьләре"ннән аерылмаячакмын, алла боерса. Ул телевизор белән бер. Телевизор карый алмасаң, "Татарстан яшьләре"н укы, барысы да бар. Мин үзем шулай эшлим.

Хушыгыз! Исән яшәгез! "Татарстан яшьләре" мең яшәсен!

Сезгә саулык, озын гомер, бәхет теләп, ВӘЛИЕВЛӘР гаиләсе.
Башкортостан, Бакалы районы, Мостафа авылы.

* * *

Мин авырып сырхауханәдә ятып, 30 март көнне терелеп чыккач, икенче көнне үк үземнең гомерем буе алып һәм яратып укый торган газетама - "Татарстан яшьләре"нә язылдым. Мин алай махсус бүләк алыр өчен, я булмаса, башка өстенлек өчен язмыйм, ә шулай да "Татарстан яшьләре"нең алдагы ярты еллыкта да 200 мең укучысы булыр дип уйлыйм. Алай гына да түгел, әле яңа укучылар өстәлер, 200 меңнән артып китәр төсле тоела.

Сезгә ихтирам белән, ГАНИЕВА Галимә Газизовна.
Казан.

* * *

Газета һичшиксез барлык яшьтәге кешеләрнең йөрәгенә юл таба алырлык. Аның тиражы ике тапкыр артып, 400.000 гә җитәргә бик мөмкин, алла боерса. Мин моны сезнең бүләгегезгә кызыгып язган дип уйламагыз. Әгәр минем фикерем барып чыкса, бәлки Казан чыгара торган яраткан тальян гармунума җиз планкалар куйдыртуда ярдәм итә алырсыз.

НӘҖМИЕВ Миргазиян Гариф улы.
Башкортостанның Ярмәкәй районы, Рәтамак авылы.

* * *

7 нче сыйныфта укыган улым Шамил төш күргән. Имеш, редакциягә барып "Татарстан яшьләре"нә язылмакчы булган. Бер җирдә дә языла алмаган. "270.000 генә иде номер, сиңа номер юк", - дип борып чыгарганнар. Ул гарьләнеп бик озак елаган. Үзем аның елаганына уянып киттем. Кырына барсам - мендәрләрен чылатып бетереп, ярсып-ярсып елап ята. Ул миңа төшен сөйләп бирде. "Әни, "Татарстан яшьләре"нең тиражы 270.000 булачак", -диде. Төшен сынап карыйк әле, кадерле дусларым, ничек булыр

Гүзәлия ШӘМСИЕВА.
Башкортостанның Агыйдел шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!

"Татарстан яшьләре"нә арзан бәядән 1 майга кадәр язылып була.

Газетаның индексы 54121, ярты елга язылу бәясе әлегә нибары 294 сум

Казан университетында ачык ишекләр көне үткәрү графигы

Факультетлар	Дата	Вакыт	Аудитория
Журфак	18 апрель	10.00	1313 аудит., корпус 2
Географак	18 апрель	10.00	1512, корпус 2
Биофак	18 апрель	10.00	баш бинаның 301 аудит
Тарих фак	18 апрель	10.00	109, корпус 2
Татфак	18 апрель	10.00	1112, корпус 2
Экофак	18 апрель	10.00	баш бинаның 209 аудит
ВМК	18 апрель	10.00	108, корпус 2.
Юрфак	25 апрель	10.00	баш бина, I физ.аудит.
Экономфак	25 апрель	10.00	109, корпус 2
Филфак	25 апрель	10.00	108, корпус 2

ТЯ

Баш мөхәррир Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ (53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2. "Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700151998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую графигы буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6077